**РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН**
**СОВЕТ**
**МОНАСТЫРСКОГО**
**СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ**
**ТЕТЮШСКОГО**
**МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА**

422392 с. Монастырское, ул. Комсомольская, 33

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ**
**ТӘТЕШ**
**МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ**
**МОНАСТЫРСК АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ**
**СОВЕТЫ**

422392 Монастырск авылы, Комсомол урамы, 33

тел., (84373) 5-45-20, факс: 5-45-20, e-mail: monastyr.tetushi@tatar.ru
ОГРН 1021606556883, ИННКПП 1638001649/163801001

# КАРАР

**15 ноябрь 2019 ел** **№ 53-1**

## Татарстан Республикасы Тәтеш муниципаль районы «Монастырск авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставына үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 06 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы, Татарстан Республикасы Тәтеш муниципаль районының «Монастырск авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставының 87 маддәсе нигезендә, Татарстан Республикасы Тәтеш муниципаль районының Монастырск авыл җирлеге Советы **КАРАР ИТТЕ:**

1. Татарстан Республикасы Тәтеш муниципаль районының Монастырск авыл җирлеге Советы тарафыннан 2015 елның 26 декабрендә кабул ителгән 6-1 номерлы Татарстан Республикасы Тәтеш муниципаль районының «Монастырск авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. 5 маддәнең 14 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«14) каты коммуналь калдыкларны туплау (шул исәптән аерым туплау) һәм транспортта ташу эшчәнлеген оештыруда катнашу;»;

1.2. 12 маддәнең 6 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«12) җирлек территориясендә яшәүче хуҗасыз хайваннар белән эш итү эшчәнлеген гамәлгә ашыру;»;

1.3. 19 маддәнең 3.1 өлешен түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«3.1. Гавами тыңлауларны оештыру һәм уздыру тәртибе Авыл җирлеге Советы карары белән билгеләнә һәм халыкка гавами тыңлаулар уздыру вакыты һәм урыны турында алдан хәбәр итүне, муниципаль хокукый акт проекты белән алдан таныштыруны, Авыл җирлеге халкының гавами тыңлауларында катнашуны, гавами тыңлауларның нәтиҗәләрен бастырып чыгаруны (халыкка җиткерүне) тәэмин итә

торган башка чараларны, кабул ителгән карарларның дәлилләнгән нигезләвен дә кертеп, күздә тотарга тиеш.»;

1.4. 22 маддәне түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«**22 маддә. Гражданнар җыены**

1. Гражданнарның җыены халыкның җирле үзидарәне турыдан-туры тормышка ашыру һәм халыкның җирле үзидарәне гамәлгә ашыруда катнашу рәвеше булып тора.
2. Гражданнар җыены «Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законда каралган очракларда һәм Татарстан Республикасы Тәтеш муниципаль районының Монастырск авыл җирлеге Советы карары белән расланган Татарстан Республикасы Тәтеш муниципаль районының Монастырск җирлеге составына керә торган торак пунктларда гражданнар җыенын әзерләү тәртибе турындагы Нигезләмә нигезендә үткәрелә.
3. “Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында” 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1 маддәсендә каралган очракларда гражданнар җыены үткәрелергә мөмкин:

1) <u>торак пунктта җирлек (муниципаль район) чикләрен үзгәртү мәсьәләсе буенча, күрсәтелгән</u> торак пункт аның составында булып, күрсәтелгән торак пункт территориясен башка җирлек (муниципаль район) территориясенә кертүгә китерә торган булса;

2) муниципаль берәмлекнең вәкиллекле органы вәкаләтләре күрсәтелгән җирлекнең чикләрен үзгәртү, үзгәртеп кору мәсьәләләре буенча гражданнар җыены тарафыннан гамәлгә ашырыла торган җирлектә;

3) әгәр сайлау хокукына ия булган җирлек халкының саны 100 дән артык кеше тәшкил итсә, җирлекнең вәкиллекле органын төзү, аның саны һәм вәкаләтләр срогы турындагы мәсьәләләрне муниципаль берәмлекнең вәкиллекле органы вәкаләтләрен гражданнар җыены гамәлгә ашыра торган җирлектә;

4) гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм куллану турындагы мәсьәлә буенча муниципаль берәмлекнең вәкиллекле органы вәкаләтләре гражданнар җыены таарафыннан гамәлгә ашырыла торган җирлектә;

5) җирлек, шәһәр эчендәге район, федераль әһәмияттәге шәһәр эче территориясе, муниципаль округ, шәһәр округы составына керә торган йә муниципаль район чикләрендә авылара территориядә урнашкан торак пунктта әлеге торак пункт территориясендә гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм куллану мәсьәләсе буенча;

6) җирлекара территориядә урнашкан торак пунктта яңа төзелгән җирлек булдыру турында халык инициативасын күрсәтү максатларында, шулай ук яңа төзелгән җирлектә, әгәр анда сайлау хокукына ия булучы халык саны 300 кешедән артмаса, яңа төзелгән җирлекнең җирле үзидарә органнары структурасын билгеләү мәсьәләсе буенча;

7) авыл халкы тыгызлыгы түбән булган территориядә яисә үтеп керүгә кыен булган җирлектә урнашып, әлеге җирлек халкының саны 100 кешедән артмаса, җирлекне бетерү мәсьәләсе буенча;

8) авыл торак пунктында авыл торак пунктының старостасы кандидатурасын күрсәтү мәсьәләсе буенча, шулай ук авыл торак пункты старостасы вәкаләтләрен вакытыннан алда туктату мәсьәләсе буенча;

9) авыл торак пунктында гражданнар җыены шулай ук, муниципаль хезмәт турында Россия Федерациясе законнарында каралган очракларда, муниципаль хезмәт вазыйфасын биләүгә конкурс үткәргәндә конкурс комиссиясе составына кандидатуралар күрсәтү максатларында үткәрелергә мөмкин.

4. Гражданнарның җыены Җирлек башлыгы тарафыннан йә сайлау хокукына ия булган, кимендә 10 кеше яши торган торак пунктта яшәүчеләр төркеме инициативасы белән чакырылырга мөмкин.

5. Җыен үткәрү инициативасын хуплап җыелырга тиешле имзалар саны сайлау хокукына ия гражданнарның, даими яисә башлыча яшәүче, торак пункт территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән, әмма 25 имзадан да ким була алмый.

6. Җирлек башлыгы тарафыннан чакырыла торган гражданнар җыены Җирлек Башлыгы карары, инициатив төркем тарафыннан чакырыла торган гражданнар җыены, Җирлек Советы карары белән билгеләнә.

7. Торак пунктта яшәүчеләр гражданнар җыенын уздыру вакыты һәм урыны турында алдан ук хәбәр ителә, Татарстан Республикасы Тәтеш муниципаль районы Монастырск тәртибе турындагы Нигезләмәдә билгеләнгән тәртип нигезендә муниципаль хокукый акт проекты һәм гражданнар җыенын хәл итүгә чыгарыла торган мәсьәләләр буенча материаллар белән алдан ук таныштырыла.

8. “Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында” 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1 маддәсендә күрсәтелгәнчә, гражданнар җыены торак пунктта яисә җирлектә яшәүчеләрнең сайлау хокукына ия булучыларның яртысыннан күбрәге катнашканда дөрес. Торак пунктта әлеге торак пунктта халыкның сайлау хокукына ия булучыларның яртысыннан артыгының бер үк вакытта бергә булу мөмкинлеге булмаган очракта, гражданнар җыены әлеге Устав нигезендә Татарстан Республикасы Тәтеш муниципаль районы Монастырск авыл җирлегенең торак пунктларында гражданнар җыенын әзерләү һәм уздыру тәртибе турындагы Нигезләмә белән расланган тәртиптә гражданнар җыенын үткәрү турында карар кабул ителгән көннән бер айдан артмаган срокта этаплап уздырыла. Шул ук вакытта, гражданнар җыенында элек катнашкан затлар, тавыш бирүнең алдагы этапларында катнашмыйлар. Гражданнар җыенының карары, гражданнар җыенында катнашучыларның яртысыннан артыгы аның өчен тавыш бирсә, кабул ителгән дип санала.

9. Җыенда кабул ителгән карарлар муниципаль хокукый актлар булып тора, Җирлек башлыгы тарафыннан имзалана һәм Татарстан Республикасының муниципаль норматив хокукый актлары регистрына кертелергә тиеш.»;

1.5. 30 маддәнең 5 өлешен түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«5. Депутат, җирле үзидарәнең сайланулы органы әгъзасы, җирле үзидарәнең сайланулы вазыйфаи заты «Коррупциягә каршы көрәш турында» 2008 елның 25 декабрендәге 273-ФЗ номерлы Федераль законда һәм башка федераль законнарда билгеләнгән чикләүләрне, тыюларны үтәргә тиеш. Депутатның, җирле үзидарәнең сайланулы органы әгъзасының, җирле үзидарәнең сайланулы вазыйфаи затының вәкаләтләре «Коррупциягә каршы көрәш турында» 2008 елның 25 декабрендәге 273-ФЗ номерлы Федераль законда, «Дәүләт вазыйфаларын биләүче затлар һәм аларның

керемнәренә башка затлар чыгымнарының туры килүен тикшереп тору турында» 2012 елның 3 декабрендәге 230-ФЗ номерлы Федераль законда, «Аерым категориядәге затларга Россия Федерациясе территориясеннән читтә урнашкан чит ил банкларында счетлар (кертемнәр) ачуны һәм булдыруны, акчалар һәм кыйммәтле әйберләр саклауны, чит ил финанс инструментларына ия булуны тыю турында» 2013 елның 7 маендагы 79-ФЗ номерлы Федераль законда, «Россия Федерациясе территориясеннән читтә урнашкан чит ил финанс инструментларына ия булуны һәм (яисә) чит ил финанс инструментларына ия булуны тыю турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законда билгеләнгән бурычларны,чикләүләрне, тыюларны үтәмәгәндә вакытыннан алда туктатыла.»;

1.6. 30 маддәнең 7 өлешен түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«7. Әлеге маддәнең 6 өлеше нигезендә үткәрелгән тикшерү нәтиҗәсендә «Коррупциягә каршы көрәш турында» 2008 елның 25 декабрендәге 273-ФЗ номерлы Федераль закон, «Дәүләт Вазыйфаларын биләүче затлар һәм аларның керемнәренә туры килүен тикшереп тору турында» 2012 елның 3 декабрендәге 230-ФЗ номерлы Федераль закон, «Аерым категориядәге затларга Россия Федерациясе территориясеннән читтә урнашкан чит ил банкларында счетлар (кертемнәр) ачуны һәм счетлар (кертемнәр) булдыруны, акчалар һәм кыйммәтле әйберләр саклауны, чит ил финанс инструментларына ия булуны һәм (яисә) алардан файдалануны тыю турында» 2013 елның 7 маендагы 79-ФЗ номерлы Федераль закон белән билгеләнгән чикләүләрне, тыюларны, бурычларны үтәмәү фактлары ачыкланганда, Татарстан Республикасы Президенты депутат, җирле үзидарәнең сайланулы органы әгъзасы, җирле үзидарәнең сайланулы вазыйфаи заты вәкаләтләрен вакытыннан алда туктату яисә күрсәтелгән затларга карата тиешле карарны кабул итәргә вәкаләтле җирле үзидарә органына яисә судка башка җаваплылык чараларын куллану турындагы гариза белән мөрәҗәгать итә.»;

1.7. 30 маддәгә эчтәлеге түбәндәгеләрдән гыйбарәт булган 7.1. һәм 7.2 өлешләрне өстәргә.:

«7.1. Үз керемнәре, чыгымнары, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында дөрес булмаган яисә тулы булмаган белешмәләр тапшырган җирле үзидарә органының сайланулы вазыйфаи затына, шулай ук хатынының (иренең) һәм балигъ булмаган балаларының керемнәре, чыгымнары, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында белешмәләр биргән депутатка, җирле үзидарәнең сайланулы органы әгъзасына, җирле үзидарәнең сайланулы вазыйфаи затына, әгәр бу мәгълүматларны бозу җитди булмаса, түбәндәге җаваплылык чаралары кулланылырга мөмкин:

1) кисәтү;

2) депутатны, җирле үзидарәнең сайланулы органы әгъзасын муниципаль берәмлекнең вәкиллекле органында, җирле үзидарәнең сайланулы органында вазыйфасыннан азат итү, аның вәкаләтләре чоры тәмамланганчы, муниципаль берәмлекнең вәкиллекле органында, җирле үзидарәнең сайланулы органында вазыйфалар биләү хокукыннан мәхрүм итү;

3) даими нигездә вәкаләтләрне гамәлгә ашырудан аның вәкаләтләре чоры туктатылганчы даими нигездә вәкаләтләр башкару хокукыннан азат итү;

4) вәкаләтләр чоры туктатылганчы муниципаль берәмлекнең вәкиллекле органында, җирле үзидарәнең сайланулы органында вазыйфалар биләүне тыю;

5) вәкаләтләре чоры туктатылганчы даими нигездә вәкаләтләр башкаруны тыю.

7.2. Депутатка, җирле үзидарәнең сайланулы органы әгъзасына, җирле үзидарәнең сайланулы вазыйфаи затына карата әлеге маддәнең 7.1 өлешендә күрсәтелгән җаваплылык чараларын куллану турында карар кабул итү тәртибе Татарстан Республикасы законы нигезендә муниципаль хокукый акт белән билгеләнә..»;

1.8. 49 маддәнең 1 өлешендәге 5 пунктның 5 абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«-каты коммуналь калдыкларны туплау (шул исәптән аерым туплау) һәм транспортта ташу эшчәнлеген оештыруда катнаша;»;

1.9. 71 маддәнең 9 өлешенә түбәндәге эчтәлекле абзац өстәргә:

«Җирлек уставы, әлеге уставка үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү турында Җирлек Советы карары «Россия Федерациясендә норматив хокукый актлар» Россия Юстиция министрлыгы порталында дәүләт теркәвенә алынганнан соң рәсми рәвештә басылып чыгарга (халыкка җиткерелергә) тиеш (http://pravo-minjust.ru, http://хокук-минюст.рф, «Интернет» челтәре басмасы сыйфатында теркәлү: Эл№ФС77 72471  2018 елның 3 мартыннан).

2. 2015 елның 26 декабрендәге 6-1 номерлы Татарстан Республикасы Тәтеш муниципаль районының Монастырск авыл җирлеге советы карары белән кабул ителгән Татарстан Республикасы Тәтеш муниципаль районының «Монастырск авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставының үзгәртелгән нигезләмәләренең яңа редакциясен хупларга.

3. Әлеге карарны «Муниципаль берәмлекләр уставларын дәүләт теркәвенә алу турында» 2005 елның 21 июлендәге 97-ФЗ номерлы Федераль законда билгеләнгән тәртиптә дәүләт теркәвенә алырга, әлеге карарны дәүләт теркәвенә тапшырырга.

4. Әлеге карарны Тәтеш муниципаль районының рәсми сайтында һәм «Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмат порталы»нда (PRAVO.TATARSTAN.RU) бастырып чыгарырга.

5. Әлеге карар дәүләт теркәвенә алынып, рәсми рәвештә басылып чыккан көннән үз көченә керә.

**Татарстан Республикасы**
**Тәтеш муниципаль районы**
**Монастырск авыл җирлеге башлыгы** **А.А. Васин**